Үткән атнанын шимбәсендә Ләмберә районынын «Алмаз» мәдәни-спорт vзәге кой һәм кvнел жырлары белән тулды – биредә Мордовия Республикасынын мәдәният, милли сәясәт һәм архив эше министрлыгы ярдәмендә Республика халык ижаты йорты, Ләмберә районынын «Алмаз» мәдәни-спорт vзәге оештырган «Авылым тавышлары» татар жыры республика фестиваль-конкурсынын гала-концерты узды. Мордовия, Татарстан республикаларыннан, Пенза, Ульян олкәләреннән 60 артык сәнгать яратучы катнашты.Катнашучыларга һәм тамашачыларга сәламләv сvзләре белән Мордовия мәдәният, милли сәясәт һәм архив эше министры урынбасары Александр Михайлович Кочеваткин; Ләмберә районы житәкчесе Александр Владимирович Белокосов һәм «Юлдаш» фермер хужалыгы житәкчесе Рафик Айяс улы Фетхуллов морәжәгать итеп кvнелне жилкәндерерлек сvзләр ишеттерделәр һәм матур теләкләр телəделәр.

Сәхнәдә Мордовия Республикасынын, Татарстан Республикасынын, Пенза һәм Ульяновск олкәләренен торле почмакларыннан килгән vзешчән артистлар балкып торды. Тамашачылар яраткан татар халык жырларын да, аларнын кайчак котелмәгән заманча интерпретацияләрен дә сокланып тынладылар. Бу конне янгыраган эстрада композицияләре монлылыгы һәм ихласлыгы белән сокландырды.

Гала-концертта катнашучы Рузаевка районыннан «Сандугачлар» ансамбле, Атюрьево районыннан Римма Теркулова, Ләмбердән Динар Латышов, Зубово-Полянадан Румия Деликамова һәм башкалар жырлары белән тамашачыны соендерделәр. Концерт программасын «СарГрад» мәдәни vсеш vзәге житәкчесе Ләйсән Байбикова «Умырзая»